КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 сентябрь г.Казань № 835

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 апрель, 314 нче; 2019 ел, 28 июнь, 521 нче; 2019 ел, 10 июль, 562 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында:

2 нче пунктта:

2.1 нче пунктчада «1,04» саннарын «0,91» саннарына алыштырырга;

2.4 нче пунктчада «1,29» саннарын «1,17» саннарына алыштырырга;

2.5 нче пунктчада «1,38» саннарын «1,27» саннарына алыштырырга;

4 нче пунктның 4.14 нче пунктчасында «Авыр менталь тайпылышлары булган балалар өчен «Чудо-Дети» дәвалау педагогикасы үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы» сүзләрен «Өстәмә һөнәри белем бирүче «Чудо-Дети» дәвалау педагогикасы үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның 5.2 нче пунктчасында «3,37» саннарын «2,94» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләтнеке булмаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгымнарны каплауга) Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көннәр санын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 16 сентябрь, 835 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләтнеке булмаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгымнарны каплауга) Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көннәр саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Оешма исеме | Хезмәт күрсәтү исеме | Бер елга койка-көннәр саны | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | стационар | ярым-стационар | озатып йөрүчеләр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Әгерҗе муниципаль районы | «Красноборская дубрава» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаҗ булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 11 414 | - | - |
| Бөгелмә муниципаль районы | «Салават күпере» («Радуга») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаҗ булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 6 633 | 6 580 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Зәй муниципаль районы | «Шатлык» («Радость») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаж булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 6 027 | 4 210 | - |
| Кама Тамагы муниципаль районы | «Камские зори» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаж булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 4 635 | 1 395 | - |
| Кукмара муниципаль районы | «Наз» («Ласка») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаж булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 7 036 | - |
| Лениногорск муниципаль районы | «Долголетие» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаж булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 3 395 | 5 851 | - |
| Менделеевск муниципаль районы | «Саулык» («Здоровье») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаж булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 7 040 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен «Надежда» Түбән Кама интернат мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 3 981 | 13 105 | 2 135 |
| | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен «Рубаха» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 630 | - |
| Саба муниципаль районы | «Балкыш» («Сияние») тернәкләндерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаҗ булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 7 597 | - | - |
| Яр Чаллы шәһәре | Яр Чаллы шәһәренең «Хезмәт ветераннары өчен пансионат» муниципаль автоном учреждениесе | тормышта авыр хәлдә калган һәм тернәкләндерү хезмәтләренә мохтаҗ булган гражданнарга социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 10 815 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | өстәмә һөнәри белем бирүче «Чудо-дети» дәвалау педагогикасы үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 17 643 | - |
| Казан шәһәре | «Крутушка шифаха-нәсе» ачык акционер-лар җәмгыяте | инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 10 123 | - | 1 470 |
| | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чик-ләнгән балаларга ярдәм күрсәтүче «Балаларда көч» хәйрия фонды | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 31 195 | - |
| | неврология авырулары белән авыручы бала-ларга һәм өлкәннәргә һәм аларның гаиләлә-ренә ярдәм күрсәтүче «Звезда» хәйрия фон-ды | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 1 548 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәренең балаларга ярдәм күрсәтүче «Поиск» диагностика һәм консультация үзәге» җирле иҗтимагый оешмасы | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 9 417 | - |
| | «ТИМА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | - | 4 325 | - |
| | «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсенең шифаханә-профилакториясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү | 12 644 | - | 1 476 |

________________________________________________